# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Җир өчен түләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Җир өчен түләү турында» Татарстан Республикасының 1992 елның 30 сентябрендәге 1767-XII номерлы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 3; 1994, № 7; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 7; 1999, № 8 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 статьяның беренче абзацында «шулай ук дәүләт милкендә, җирле үзидарә милкендә булган җирләрне гражданнар һәм юридик затлар милкенә, мирас итеп калдырылучы гомерлек биләүгә, файдалануга, шул исәптән, торак пунктының инженерлык һәм табигатьне саклау инфраструктурасын да кертеп, арендага тапшырганда аренда түләве һәм бер тапкыр алынучы түләүләр», дигән сүзләрне «аренда түләве, җирнең норматив бәясе» дигән сүзләргә алмаштырырга.

2. 7 статьяның икенче өлешен төшереп калдырырга.

3. 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. Җир салымы түләүдән Федераль закон нигезендә түбәндәгеләр тулысынча азат ителәләр:

1) тыюлыклар, милли һәм дендрология парклары, ботаника бакчалары;

2) аз санлы халыклар һәм этник төркемнәр яши һәм хуҗалык итә торган урыннарда традицион промыселлар белән, шулай ук аларның традицион көнкүреш урыннарында нәфис халык промыселлары һәм халык кәсепләре белән шөгыльләнүче предприятиеләр, шулай ук гражданнар;

3) авыл хуҗалыгына һәм урман хуҗалыгына караган фәнни оешмалар, фәнни-тикшеренү һәм уку йортларының тәҗрибә, эксперименталь һәм уку-тәҗрибә хуҗалыклары, шулай ук башка профильдәге фәнни

учреждениеләр һәм оешмалар фәнни, фәнни-эксперименталь, укыту максатларында һәм авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы культуралары сортларын сынау өчен турыдан-туры файдаланыла торган җир кишәрлекләре өчен;

4) тиешле бюджетлар акчалары исәбенә йә һөнәр берлекләре акчалары исәбенә финансланучы сәнгать, кинематография, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре, социаль хезмәт күрсәтүнең дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре (курорт учреждениеләреннән гайре), финанс чыганакларына бәйсез рәвештә балалар савыктыру учреждениеләре, табигатьне, тарих һәм мәдәният ядкярләрен саклауның дәүләт органнары, шулай ук үз җирләрендә үзләре файдалана торган тарих, мәдәният һәм архитектура ядкярләре буларак дәүләт тарафыннан саклана торган биналар булган дини берләшмәләр;

5) бозылган (рекультивацияләүне таләп итүче) җирләрне авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен алганда, файдалануның баштагы 10 елына, яисә туфракның уңдырышлылыгын күтәрүдә файдаланыла торган торф чыгару максатларында алган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук гражданнар;

6) Бөек Ватан сугышында катнашучылар, шулай ук законнар белән Бөек Ватан сугышында катнашучыларның социаль гарантияләре һәм өстенлекле ташламалары кагылган гражданнар;

7) I һәм II төркем инвалидлар;

8) Россия Федерациясенең дәүләт чиге буенча күзәтү полосасы биләгән җирләр;

9) торак пунктларның уртак файдаланудагы җирләре;

10) финанслау чыганагына бәйсез рәвештә мәдәният, физик культура һәм спорт, туризм, спорт-савыктыру юнәлешендәге учреждениеләр һәм спорт корылмалары (спорт корылмалары, физкультура-спорт учреждениеләре профилендә булмаган эшчәнлектән гайре);

11) Россия фәннәр академиясенең, Россия медицина фәннәре академиясенең, Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясенең, Россия мәгариф академиясенең, Россия архитектура һәм төзелеш фәннәре академиясенең югары уку йортлары, фәнни-тикшеренү учреждениеләре, предприятиеләре һәм оешмалары, дәүләти фәнни үзәкләр, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган исемлек буенча Россия Федерациясе министрлыкларының һәм ведомстволарының югары уку йортлары һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре;

12) дәүләт элемтә предприятиеләре, акцияләренең контроль пакеты дәүләтнеке булган, дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар программаларын таратуны (трансляцияләүне) тәэмин итүче, шулай ук Россия Федерациясе оборонасы мәнфәгатьләрендә эшчәнлек алып баручы

элемтә акционер җәмгыятьләре, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының су юллары һәм гидрокорылмалары дәүләт предприятиеләре, диңгез һәм елга транспорты предприятиеләре, дәүләт учреждениеләре һәм оешмалары, шул исәптән су каплаган җирләр һәм гидротехник корылмалар төзегәндә ясалма рәвештә барлыкка китерелгән территорияләр өчен, уртак файдаланудагы федераль автомобиль юллары, аэродромнар, аэропортлар һәм граждан авиациясен төзекләндерү заводлары, федераль милеккә кертелгән аэронавигация корылмалары һәм объектлары биләгән җирләр өчен;

13) предприятиеләр, фәнни оешмалар һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре Россия Федерациясенең мобилизация резервларына салынган матди кыйммәтләрне саклауда турыдан-туры файдаланылучы җир кишәрлекләре өчен;

14) дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары эшчәнлеген, шулай ук Россия Федерациясе оборона министрлыгы эшчәнлеген тәэмин итү өчен бирелүче җирләр;

15) дәүләт һәм муниципаль, шулай ук һөнәр берлекләре милкендә булган шифаханә-курорт һәм савыктыру учреждениеләре, ял учреждениеләре;

16) эчке, тимер юл һәм чик буе гаскәрләре, граждан оборонасы гаскәрләре, аларны урнаштыру һәм даими эшчәнлек өчен бирелгән җирләр өчен;

17) Чернобыль АЭСындагы афәт, граждан һәм хәрби билгеләнештәге атом объектларындагы радиация һәлакәтләре, шулай ук атом-төш коралын һәм космик техниканы да кертеп, атом-төш җайланмаларының теләсә кайсы төрләренә бәйле сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр нәтиҗәсендә радиациягә дучар ителгән гражданнар;

18) хәрби хезмәткәрләр, хәрби хезмәттә булуның иң чик яшенә җитеп, сәламәтлегенең торышына яисә оештыру-штат чараларына бәйле рәвештә хәрби хезмәттән азат ителгән, җәмгысе егерме ел һәм аннан да күбрәк хәрби хезмәттә булган гражданнар, хәрби хезмәткәрләрнең һәм эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең, җинаять-җәза үтәү системасы учреждениеләре һәм органнары хезмәткәрләренең, алар хезмәт итү вазыйфаларын башкарганда туендыручыларын югалткан гаилә әгъзалары;

19) Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Дан, Хезмәт Даны һәм «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнарының тулы кавалерлары;

20) җинаять-җәза үтәү системасы учреждениеләре һәм органнары;

21) һәлакәттән коткару буенча профессиональ хезмәтләр, һәлакәттән коткару буенча профессиональ формированиеләр;

22) янгыннан саклану хезмәте файдалана торган җирләр;

23) дәүләт сугару системаларын һәм аерым урнашкан гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре, шул исәптән бүлү полосалары чикләрендә сусаклагычлар, каналлар, дамбалар һәм башка гидротехник корылмалар биләгән су фонды җирләре өчен дә, шулай ук дәүләт сугару системаларын һәм аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзүче дәүләт унитар предприятиеләре һәм дәүләт учреждениеләре үзләренә әлеге объектларны төзү өчен вакытлыча бирелгән җирләр өчен.

Беренче тапкыр крестьян (фермер) хуҗалыклары оештыручы гражданнар, аларга җир кишәрлекләре бирү мизгеленнән алып, биш ел дәвамында җир өчен түләүдән азат ителәләр.

Тимер юл бүлү полосасында урнашкан җирләр өчен салым тимер юл транспорты предприятиеләреннән, учреждениеләреннән һәм оешмаларыннан авыл хуҗалыгы җирләре өчен федераль законнар билгеләгән җир салымы ставкасының 25 процентына кадәр күләмдә алына.

Җир салымын түләүдән азат ителгән юридик затлар һәм гражданнар җир кишәрлекләрен арендага (файдалануга) тапшырганда, алардан арендага (файдалануга) бирелгән мәйдан өчен җир салымы алына.

4. 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья. Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешендә җир салымы түләүдән түбәндәгеләр азат ителәләр:

1) рекультивацияләүне таләп итүче бозылган җирләрне авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен алучы предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук гражданнар, әлеге Законның 12 статьясының 5 пунктында әйтелгән 10 ел узганнан соң, файдалануның аннан соңгы 5 елына;

2) авыл җирендә яшәгән һәм пенсиягә чыккан III төркем инвалидлар, ялгыз пенсионерлар;

3) урман торгызу, урман үрчетү, урманнарны саклау һәм яклау буенча эшләр башкаручы урман хуҗалыгы оешмалары;

4) эшкәртү предприятиеләренең санитария-терлек чалу пунктлары;

5) уртак файдаланудагы автомобиль юлларын һәм юл корылмаларын карап торучы оешмалар, әлеге юллар һәм корылмалар биләгән җирләр өчен;

6) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый торган исемлек буенча фәнни-тикшеренү учреждениеләре;

7) инвалидларның җәмәгать берләшмәләре, алар милкендәге оешмалар, устав капиталлары тулысынча инвалидларның җәмәгать берләшмәләре кертемнәреннән торган хуҗалык җәмгыятьләре;

8) Татарстан Республикасы милкенә кертелгән граждан авиациясе аэродромнары, аэропортлары һәм төзекләндерү заводлары, аэронавигация корылмалары һәм объектлары биләгән җирләр өчен оешмалар.

Мобилизация билгеләнешендәге объектлар, консервацияләнгән һәм агымдагы җитештерүдә файдаланылмаучы мобилизация куәтләре, сынау полигоннары урнаштырылган җирләр өчен җир салымы һәм аренда түләве Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешендә алынмый.».

5. 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14 статья. Җирле үзидарә органнары федераль законнарда билгеләнә торган тәртиптә җир салымы буенча өстенлекле ташламалар билгеләргә хокуклы.».

6. 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18 статья. Җир салымын түләүче тарафыннан җир өчен түләү түбәндәгечә күчерелә:

җирле үзидарә гамәлгә ашырылучы территорияләр чикләренә керүче җирләр һәм җирле үзидарә органнары карамагына тапшырылган башка җирләр өчен, - җирле үзидарә органнарының бюджет счетларына;

җирле үзидарә органнары карамагына тапшырылган җирләрдән тыш, шәһәрләр һәм районнар чикләренә керүче җирләр өчен, - федераль казначылык органнары счетларына.».

7. 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19 статья. Шәһәрләр һәм поселоклар җирләре өчен җир салымы һәм аренда түләве акчаларын барлык дәрәҗәдәге бюджетлар арасында бүлешү законнар нигезендә билгеләнә.

Авыл хуҗалыгы җирләре өчен җир салымы һәм аренда түләве акчаларын бүлешү «Җир өчен түләү турында» Россия Федерациясе Законының 5 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып, чираттагы финанс елына бюджет системасы турында Татарстан Республикасы Законында ел саен билгеләнә. Татарстан Республикасында үзәкләштерелеп башкарылучы, әлеге Законның 23 статьясында каралган гамәлләр өчен Татарстан Республикасының республика бюджетына Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджетына күчерелергә тиешле җир салымы акчалары суммасыннан ун процентыннан да артык булмаган өлеше күчерелә.».

8. 24 статьяның өченче өлешендәге «,шулай ук шәһәрләрдә һәм поселокларда инженерлык һәм табигатьне саклау төзелмәләрен торгызу өчен бер тапкыр бирелә торган түләүләрне билгеләгәндә» дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

9. 25 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 статья. Җирнең норматив бәясе законнар нигезендә билгеләнә.».

**2 статья.** Әлеге Закон 2002 елның 1 гыйнвареннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер айдан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 20 сентябре
№ 1059